ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12-нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ　　　　　　　　　　КАРАР

28 12 2020 г. № 1012

Түбән Кама муниципаль районы җирлекләрендә торак урыны өчен түләү билгеләү турында

Россия Федерациясе Торак Кодексының 14 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. Түбән Кама муниципаль районы җирлекләрендә социаль наем шартнамәләре һәм дәүләт яисә муниципаль торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннарын наемга алучылар өчен торак урыннардан файдаланган өчен һәм Түбән Кама муниципаль районында күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлап алу турында карар кабул итмәгән күпфатирлы йортларның торак урыннары милекчеләре өчен түләү күләмен расларга һәм 2021 елның 1 гыйнварыннан гамәлгә кертергә һәм 2021 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә дип санарга (кушымта).

2. Түбән Кама муниципаль районы җирлекләрендә үзенең гомуми җыелышында торак урынны карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән күпфатирлы йортларның милекчеләре өчен 2021 елның 1 гыйнварыннан 2021 елның 31 декабренә кадәрге чорга торак урынны карап тоту өчен түләү әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән күләмдә раслана.

3. Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының «Түбән Кама муниципаль районы җирлекләрендә торак урыны өчен түләү билгеләү турында» 2019 елның 26 декабрендәге 917 номерлы карарын 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Житәкче　　　　　　　　　　　　　　　　А.Г. Сәйфетдинов

Татарстан Республикасы
Түбән Кама муниципаль районы
Башкарма комитетының
2020 елның «28» 12
1012 номерлы карары белән расланган
кушымта

Түбән Кама муниципаль районы җирлекләрендә социаль наем шартнамәләре һәм дәүләт яисә муниципаль торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннарын наемга алучылар өчен һәм Түбән Кама муниципаль районында күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлап алу турында карар кабул итмәгән күпфатирлы йортларның торак урыннары милекчеләре өчен торак урынны карап тоту өчен 2021 елның 1 гыйнварыннан 2021 елның 31 декабренә кадәр чорга түләү күләме

| т/с | Түләү исеме | Үлчәү берәмлеге | Түбән Кама шәһәре | Кама Аланы шәһәр тибындагы поселогы | Авыл җирлекләре | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | Красный Ключ, Афанас | Каенлы, Иске Чишмә, Кызыл Чапчак, Түбән Уратма, Майская Горка, Шәңгәлче, Макаровка | Ширәмәт, Сухрау |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
| 1 | Торак фонды белән идарә итү | айга торак бинаның гомуми мәйданы сум/кв.м. | 3,47 | 3,29 | 3,47 | 2,10 | 1,09 |
| 2 | Йорт эчендәге гомуми файдаланудагы урыннарны җыештыру | айга торак бинаның гомуми мәйданы сум/кв.м. | 3,25 | 4,50 | 3,25 | 2,45 | 1,63 |
| 3 | Йорт яны территориясен җыештыру | айга торак бинаның гомуми мәйданы сум/кв.м. | 3,40 | 2,89 | 3,40 | 3,73 | 2,33 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 4 | Чүп үткәргечкә хезмәт күрсәтү | айга торак бинаның гомуми мәйданы сум/кв.м. | 1,70 | 1,69 | - | - | - |
| 5 | Торак биналарны агымдагы ремонтлау һәм йорт яны территориясен төзекләндерү | айга торак бинаның гомуми мәйданы сум/кв.м. | 3,22 | 2,83 | 3,22 | 2,77 | 2,66 |
| 6 | Йорт эчендәге су-канализация челтәрләренә техник хезмәт күрсәтү һәм агымдагы ремонт ясау | айга торак бинаның гомуми мәйданы сум/кв.м. | 2,74 | 2,12 | 2,74 | 1,84 | 1,69 |
| 7 | Җылылык алмашу җиһазлары белән җиһазландырылган йорт эчендәге су-канализация челтәрләренә техник хезмәт күрсәтү һәм агымдагы ремонт ясау | айга торак бинаның гомуми мәйданы сум/кв.м. | 3,01 | - | - | - | - |
| 8 | Йорт эчендәге үзәк җылыту челтәрләренә техник хезмәт күрсәтү һәм агымдагы ремонт ясау | айга торак бинаның гомуми мәйданы сум/кв.м. | 2,67 | 1,43 | 2,67 | - | 1,20* |
| 9 | Йорт эчендәге электр челтәрләренә техник хезмәт күрсәтү һәм агымдагы ремонт ясау | айга торак бинаның гомуми мәйданы сум/кв.м. | 0,95 | 1,13 | 0,95 | 1,00 | 1,09 |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
| 10 | Йорт эчендәге газ челтәрләренә техник хезмәт күрсәтү һәм агымдагы ремонт ясау | айга торак бинаның гомуми мәйданы сум/кв.м. | 0,23 | - | 0,23 | 0,23 | 0,23 |
| 11 | Дератизацияләү (дезинсекцияләү) | айга торак бинаның гомуми мәйданы сум/кв.м. | 0,17 | 0,17 | 0,17 | 0,17 | 0,17 |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 12 | Наемга түләү (наемга алучыларга) | айга торак бинаның гомуми мәйданы сум/кв.м. | Методика нигезендә дифференцияләнгән | | | | |
| 13 | Лифтларга хезмәт күрсәтү | айга торак бинаның гомуми мәйданы сум/кв.м. | 3,59 | 4,84 | - | - | - |
| 14 | Техник чараларга һәм янгын сүндерү һәм төтен суырту системаларына хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау (хезмәт күрсәтү булганда) | айга торак бинаның гомуми мәйданы сум/кв.м. | 1,03 | - | - | - | - |
| 15 | Чүп үткәргечсез күпфатирлы йортлар буенча чүп контейнерларын карап тоту (хезмәт күрсәтү булганда) | айга торак бинаның гомуми мәйданы сум/кв.м. | 0,19 | - | 0,19 | 0,19 | 0,19 |

Искәрмә:

* тариф Ширәмәт авыл җирлеге буенча билгеләнгән